КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 июль г.Казань № 593

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 23 ноябрь, 961 нче; 2012 ел, 15 май, 378 нче; 2014 ел, 11 июнь, 398 нче; 2014 ел, 27 ноябрь, 920 нче; 2015 ел, 17 апрель, 259 нчы; 2015 ел, 14 декабрь, 946 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Бу Тәртип максатларында түбәндәге терминнар кулланыла:

административ регламент – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралары һәм административ гамәлләре вакытларын һәм эзлеклелеген, аның структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары арасында үзара хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәтләре күрсәтүдән файдаланучылар), дәүләт хакимиятенең һәм җирле үзидарәнең башка органнары, шулай ук оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген билгели торган норматив хокукый акт;

дәүләт хезмәте – федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен тормышка ашыру буенча (дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә гариза бирүчеләрнең сораулары буенча гамәлгә ашырыла торган) эшчәнлек;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга карата шикаять (алга таба – шикаять) – гариза бирүченең яки аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре йә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлештә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләре тарафыннан гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланганда бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турындагы таләбе;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль (шул исәптән автоном учреждение булып торучы) учреждениенең оештыру-хокукый рәвештә төзелүче, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне (шул исәптән электрон рәвештә) оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү – гариза бирүченең дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы тиешле соравы яки «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган, ә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар белән үзара хезмәттәшлек итү күпфункцияле үзәк тарафыннан норматив хокукый актлар һәм үзара хезмәттәшлек турындагы килешү нигезендә гариза бирүчедән башка гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә караган читтән торып эшли торган урын – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 ел, 22 декабрь, 1376 нчы карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең

күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә караган территориаль аерымланган структур бүлекчә (офис)».;

1.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләре буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең бертип административ регламентлары эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан эшләнә һәм җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәтләре күрсәтүне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләре барлыкка килгән көннән иң күбе 60 календарь көн эчендә әлеге дәүләт хакимияте башкарма органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

2.2 нче пунктның «д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлеше нигезендә күпфункцияле үзәк функцияләрен тормышка ашыруга җәлеп ителүче оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, эшчеләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе.»;

2.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Гомуми нигезләмәләргә караган бүлек түбәндәге бүлекчәләрдән тора:

а) административ регламентны җайга салу предметы;

б) дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның ташламалы категорияләрен (затлар категориясен) (булганда) күрсәтеп, дәүләт хезмәтләре күрсәтүдән файдаланучылар – юридик һәм физик затлар исемлеге китерелә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүдән файдаланучылар категорияләре;

в) түбәндәгеләрне үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүматны бирү тәртибенә карата таләпләр:

дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органнарының, аларның структур бүлекчәләре һәм территориаль органнарының, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат, дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен мөрәҗәгать итәргә кирәк булган дәүләт һәм муниципаль органнар һәм оешмаларның, шулай ук дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә караган читтән торып эшли торган урыннарның урнашу урыннары һәм эш графиклары турында мәгълүмат алу ысуллары;

дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органнарының структур бүлекчәләре, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларның белешмә телефоннары, шул исәптән автомат рәвештә мәгълүмат бирүче җайланманың телефон номеры;

башкарма хакимият органнарының, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт

хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү турындагы мәгълүматны үз эченә алган рәсми сайтлары адреслары, аларның электрон почта адреслары;

гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат, әлеге хезмәтләр күрсәтү барышы турында белешмәләр (шул исәптән «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын һәм «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасын файдаланып) алу тәртибе;

бу пунктчада күрсәтелгән мәгълүматны урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү урыннарындагы стендларда, шулай ук башкарма хакимият органнарының, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында, шулай ук «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәм «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру тәртибе, формасы һәм урыны;

дәүләт хезмәтләре күрсәтү урыннарындагы стендларда түбәндәге мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштыру турында таләпләр:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтенең исеме;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып), Россия Федерациясе законнары белән туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты;

дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза (Россия Федерациясе законнары белән документларны ирекле рәвештә тапшыру күздә тотылмаган очраклардан тыш), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәк булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиеш булган документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең алардан (шул исәптән электрон рәвештә) файдалану ысуллары, аларны тапшыру тәртибе;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәткән, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү күләме;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының эш вакыты турында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы

белгечләренең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны кабул итү графигы турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүдән файдаланучылар өчен дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) карата судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирүгә аларның хокуклары турында мәгълүмат;

г) норматив хокукый актлар реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;

д) административ регламентта кулланыла торган терминнар һәм аларның билгеләмәләре.»;

2.9 нчы пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлеше нигезендә күпфункцияле үзәк функцияләрен тормышка ашыруга җәлеп ителә торган оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, эшчеләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибенә караган бүлектә түбәндәгеләр күрсәтелә:»;

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучының шикаяте (дәгъвасы) судка кадәрге (судтан тыш) тәртиптә адресланырга мөмкин булган дәүләт хакимияте органнары, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлеше нигезендә күпфункцияле үзәк функцияләрен тормышка ашыруга җәлеп ителә торган оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары;»;

3.1 пунктның «б» пунктчасында «24 көн» сүзләрен «15 көн» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин